Балалар кара-каршы тезелгән урындыкларда ял итеп утыралар. Тәрбияче аларга «сәяхәткә чыгарга» тәкъдим ясый. Балалар урыннарыннан торалар, бер-бер артлы тезелеп, тәрбияче артыннан баралар. Тәрбияче: «Тигез юлдан барабыз», – дигәндә, балалар колоннада гади адым белән атлап баралар, «Ташлык җирдән барабыз», – дигәндә, таштан ташка сикергән кебек, ике аякта сикерәләр. Шулай аралаштырып, уенны 2–3 тапкыр кабатлагач, тәрбияче: «Барыбыз да чокырга төштек, бух!» – ди, барысы да чүгәлиләр. «Чокырдан чыктык», – диюгә күтәреләләр. Уен кабатлана. Ахырдан тәрбияче: «Менә безнең өебез, өйгә кереп утырыгыз», – дигәч, балалар үз урыннарына йөгерәләр.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе “4нче номерлы “Ләйсән” гомумүсеш төрендәге балалар бакчасы”

***Уйный***

***Үсәбез***

***Уйный***







**Кара урманда, аю янында**

Мәйданчыкның (бүлмәнең) бер читендә «аю өне» – җиргә сызып ясалган түгәрәк билгеләнә. Балалар арасыннан берсе «аю» итеп сайлана. Ул үз өнендә утыра. Барлык башка балалар, гөмбә, җиләк җыйган булып кыланып, әкрен генә аю янына баралар һәм түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Аю бабай урманында
Җиләк, гөмбәләр җыям,
Аю бабай күрмәсен,
Без йөргәнне сизмәсен!

Әлегә кадәр йокымсыраган кыяфәттә утырган аю бу сүзләрдән соң кыймылдый, киерелә башлый һәм өненнән (түгәрәктән) чыга. Балалар төрле якка йөгерешәләр, аю аларны куа. Тотылган бала аю ролен үти.

Уенга күрсәтмәләр

• Балаларга уйнаганда «аюдан» курыкмаска, «аю» куа башлагач кына йөгерергә кирәклеген аңлатырга кирәк.

**Куык**

Уйнаучылар, тыгыз итеп тезелеп, кечкенә түгәрәк ясыйлар. Кулга-кул тотынышып, түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, артка таба чигенәләр, әкрен генә түгәрәкне киңәйтәләр:

Өрел, куык, зур булып,
Тик шартлый күрмә, тулып;
Һаман да син бул матур –
Күпереп, кабарып тор!

Зур, киң түгәрәк ясала. Тәрбияче: «Куык шартлады!» – дигәннән соң, балалар, кулларын ычкындырып, тиз генә кул чабалар (куык шартлаган тавыш чыгаралар) һәм «Һоп!» дип чүгәлиләр. Куык яңадан өрелә, уен кабатлана.

**Тавыклар яшелчә бакчасында**

Җирдән 50 см биеклектә ике агач арасына бау тарттырыла – «бакча» чиге билгеләнә. Балалар «тавыклар» булалар. Тәрбияче, бакча караучысы булып, бакчада утыра. Каравылчы йокыга киткәч, тавыклар бау астыннан бакчага керәләр. Бакча караучысы уяна да, «Көш-көш!» дип, тавыкларны куа, тавыклар йөгерешеп китәләр. Аннан соң уен яңадан кабатлана.

**Кем тизрәк?**

Уен өчен балалар санынча кызыл һәм зәңгәр төстәге флаглар кирәк. Балалар, кулларына флаглар тотып, музыка яки бубен шалтыравы астында төрле юнәлештә йөриләр. Тәрбиячenең «Тукта!» дигән сүзенә балалар туктап калалар. Тәрбияче, бер читкә китеп: «Бер, ике, өч, барыгыз да монда куч!» – ди һәм кызыл (яки зәңгәр) флагны күтәрә. Кызыл флаг тоткан балалар тәрбияче янына җыелалар.

Уен 2–3 тапкыр кабатлана.

**Тигез юл буйлап**

Уен бер-бер артлы тезелеп бару, ике аякта сикерү хәрәкәтләрен камилләштерергә ярдәм итә.